Харисова, Э. Чаллы халык театры тарихында 2 нче мәктәп / Э. Харисова // Мәйдан. – 2023. – №5 (258). – Б. 116-124.

# Чаллы халык театры тарихында 2 нге мәктәп

## Чаллы халык театрының кыскача тарихы

1918 елда Чаллы татар драма театры коллективы үзенең беренче адымнарын ясый. Кызылармеецлар ярдәме белән Мәркәз (хәзерге Үзәк) урамындагы байлардан калган бер склад клуб - нардом (народный дом) итеп җиһазландырыла. Шунда кечкенә пьесалар уйнала, концертлар куела башлый.

1918 елның ноябрь аенда беренче тамаша күрсәтелә. Күп вакыт хатын-кызлар ролен ир-егетләргә башкарырга туры - килә. Нурулла Гарифуллин, Фәхрул ла Гыйззәтуллин, Афзал Гыйльманов, Зәки Хәсәншин, Габитовлар татар дра ма түгәрәгенең беренче карлыгачлары була.

1923-1924 елларда, шул урамдагы тоз складларын чистартып, кинотеатр төзелә, сәхнә корыла. Кинолар тәмамлангач, һәвәскәрләр пьесалар да куялар. Үзешчәннәр уйнаган беренче әсәр - К. Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар» драмасы.

Чаллыда «Трактор» газетасын оештырып киткән Нур Баян 1932-1933 елларда коллектив өчен «Гүбәнә суы буенда» дигән сәхнә әсәрен яза һәм үзе дә сәхнәләштерүдә ярдәм итә.

Заман шул чор сулышына туры килерлек әсәрләр сорый. 1938 елда Һ. Такташның «Күмелгән кораллар» исемле пьесасы сәхнәгә куела. Өяз комиссары Мансур ролен - Сафа





Вәлитов, авыл укытучысы Сәгыйдә ролен Нурлыһәдә башкара. Уналты яшьлек Хәниф Гомәров бу пьесада үзенең беренче ролен - комиссарның энесе Рөстәмне уйный. Кызыл командир, сәхнәгә чын атта чыгып, тамашачыларны таң калдыра.

Рус классикларының әсәрләрен татарчалаштырып, репертуарларына кертә башлыйлар. Мәсәлән, Н. Островскийның «Гаепсездән гаеплеләр» пьесасы куелу - татар драма төркеме зур югарылыкта булуын күрсәтүче мисал.

1936 елдан түгәрәкнең составы тагы да яшәрә. Тамашачы яңа әсәрләр белән таныша. Кәрим Тинчуринның «Зәңгәр шәл», Таҗи Гыйззәтнең «Талир тәңкә», «Ялкын» һәм Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану», «Асылъяр» һ.б. яңартылып, кабатланып күрсәтелә.

1935-1938 елларда театрның төп репертуарын классик әсәрләр алып тора. Бу елларда Хәниф Гомәров, Мәрьям Шәйдуллина, Мансур Кашапов, Разия Фәрхетдинова, Зәйнәп Җиһаншина

һәм башкалар иҗат эшләрен башлап җибәрә. Коллективта 2 нче мәктәп укучылары төп составны тәшкил итә.

1940 елны драма түгәрәге беренче тапкыр смотрда катнаша һәм югары бәя ала. Биль Белорецкийның «Чик сакчылары» пьесасы сугышка кадәр куелган соңгы әсәр була. Куючы һәм төп рольне башкаручы - баш врач С. Б. Сабитова.

Бөек Ватан сугышы башлана. Драмтүгәрәкнең төп көчләре сугышка китә. Ләкин коллектив таркалмый, эшчәнлеген активлаштыра гына. Беренчедән, ул, сәхнәдә совет халкының батырлыгын күрсәтеп, изге көрәшкә өнди. Икенчедән, җыелган акча оборона фондына яки ятим калган балаларга, авыр тормышлы гаиләләргә тотыла. Бу елларда драмтүгәрәк «Канга - кан», «Ватан кызлары», «Төнге сигнал», «Мәрьям», «Югалган кыз», «Җәмилә» пьесаларын сәхнәләштерә. 2 нче мәктәптә укыган Мәрьям Шәйдуллинага хәрби комиссариаттан чакыру кәгазе сәхнә артында тапшырыла. Ул сер бирми, спектакльне ахырына кадәр уйный. Спектакль беткәч, сәхнәгә чыгып, яраткан тамашачылары белән хушлашып, сугышка чыгып китә. Сугышның авыр юлларын урап, исән-сау туган коллективына кайта.

1944-1945 елларда 2 нче мәктәпне тәмамлаган Хәниф Гомәров, Васил Кашапов, Салих Шәйдуллин, Гайни Батыршин фронттан кайталар һәм яңадан үзешчән сәнгатьтә катнашып китәләр. Репертуар Газиз Иделленең «Дәүләт Бәдриев», Габдрахман Минскийның «Дуслык күпере» әсәре һ.б. пьесалар белән баетыла. Тамашаларны халык бик җылы кабул итә.

Ул елларда баянчы Фәрит Мәүҗиев, Ләлә Әхмәтҗанова, Асия Зиатдинова һәм башкалар агитбригада эшен дә җанландырып җибәрәләр. Туклану һәм транспорт ягы начар, артистлар, кар яки саз ерып, авылдан авылга җәяү йөриләр. Аруларын сиздермичә, халык күңелен күтәрәләр.

*«Түләүле штат юк, бары энтузиастлар гына. Киемнәрне шәһәр халкыннан сорап торабыз, сәхнә җиһазларын өйдән алып киләбез. Репетицияләрне төрле урыннарда, хәтта аерым фатирларда да уткәрергә туры килә. Спектакльләр еш кына кинотеатр сәхнәсендә, киносеанс тәмамлангач куела. Кергән акча костюмнар, декорация, аренда өчен тотыла»,* - дип искә ала Мансур Кашапов.

Ниһаять, 1949 елда драмтүгәрәккә штат һәм район Культура йортыннан бер бүлмә бирелә. Мансур Кашапов сәнгать җитәкчесе итеп билгеләнә. Сугыштан соңгы елларда смотрлар активлаша. Драмтүгәрәк ул смотрларда, зур күләмле әсәрләр куеп, бик күп Мактау кәгазьләре белән бүләкләнә. Мисал өчен, Таҗи Гыйззәтнең «Ялкын», «Чын мәхәббәт» әсәрләре Мәскәү вәкилләре катнашындагы комиссия тарафыннан югары бәя ала. Куючысы - Гомәр Мөхәммәтҗанов.

1949-1954 елларда сәхнәгә бик күп классик әсәрләр куела, коллективның дәрәҗәсе тагын да арта.

1951 елда Чаллыда зур мәдәният йорты төзелә. Драма түгәрәге әгъзалары төзелештә үзләре дә катнаша. Мансур Кашаповка, 1951-1954 елларда ФЗУда уку, соңрак чирәм җирләрне күтәрергә китү сәбәпле, иптәшләреннән аерылып торырга туры килә. Коллектив җитәкчесе итеп профессиональ белемле режиссер Роза Талипова килгәч, Таҗи Гыйззәтнең «Чаткылар», Гөлшат Зәйнәшеваның «Рамай», Шаһиморат

Зәйнинең «Энҗе бөртекләре» кебек пьесалары сәхнәгә куела. Хәниф Гомәров, Гайни Батыршин, Нәсимә Гарипова, Әминә Мортазина, Равия Булатова, Зәйнәп Җиһаншина, Мәрьям Шәйдул- лина, Салиха Хәбибрахманова, Әсма Шәйхетдинова, Мәүгыйдә Фазлыева, Разия Фәрхетдинова һ.б. сәхнә ветераннары коллективның төп көче булып кала. Төркемгә Саҗидә Нургалиева, Рәшат Таишев, Котдус Мөхәммәтшин, Таймас Галиев, Биҗан Хөрмәтуллин кебек яшьләр килеп кушыла. Коллектив 1958 елда үзенең 40 еллыгын К. Тинчуринның «Зәңгәр шәл»ен куеп каршылый. Спектакль Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә зур уңыш белән үтә. Коллектив Татарстан Югары Советының Мактау кәгазе белән бүләкләнә.

1960 елда Мансур Кашапов кабат драма түгәрәгенең сәнгать җитәкчесе итеп билгеләнә. Театр һәрвакыт профессиональ театр әһелләре белән тыгыз элемтәдә эшли. СССРның халык артисты Хәлил Әбҗәлилов, ТАССР-ның атказанган сәнгать эшлеклесе Сәет Булатов, Татарстанның халык артисты, режиссер Хәким Сәлимҗанов һәм башкалар коллективка ярдәм итеп торалар. Репертуар байый һәм сыйфат яхшыра. Ниһаять, 1962 елда коллективка «Халык театры» исеме бирелә.

1965 елда театр Бөтенроссия смот-рына чакыру ала. Тик Мәскәү «Ялкын»ны түгел, ә «Зәңгәр шәл»не сорый. Өч ел элек уйналган әсәрне яңадан торгызу кирәк була. Бер атна эчендә 80 кешедән торган спектакль Чаллы сәхнәсенә чыгарыла. Казанда Академия театры сәхнәсендә репетицияләр башлана. Музыкаль әсәрне оркестр белән уйнау үзешчәннәргә җиңел бирелми. Ниһаять, 22 февральдә коллектив башкалага юнәлә. Башта ул Кремль сарае сәхнәсендә зур комиссия алдында имтихан тота. 23 февральдә коллектив халык театрларының Бөтенроссия декадасын башлап җибәрә.

Мансур Кашапов истәлекләреннән: *«Спектакльнең барышы турында җентекләп яза алмыйм. Каушавым, шулкадәр көчле булды, мин коридорга чыгып утыргычка утырдым да репро-дуктордан спектакльне тыңладым. Спектакль беткәч, мине, коридордан эзләп табып, баш ияргә сәхнәгә чакыр-дылар. Карасам, залда мәхшәр диярсең: тамашачылар сәхнәгә менәрдәй булып алкышлыйлар, безне сәхнәдән җибәрмиләр! Пәрдә биш-алты тапкыр ябылып ачылгандыр. Ул чәчәкләр яуганын күрсәгез!»*

Бөтенроссия конкурсында Чаллы халык театрының лауреат исемен яулап алуы искиткеч могҗиза була. Коллектив чыгышы «Огонек» журналы тышлыгын бизи.

Казанда коллективны зур тантана белән каршылыйлар. Кремльдә аларны Югары Совет Президиумы әгъзалары, Батыев үзе кабул итә. Югары Совет Президиумы Указы нигезендә коллективка, режиссер Мансур Кашаповка, Хәниф Гомәровка, Мәрьям Шәйдуллинага (өчесе дә 2 нче мәктәптә белем алган!), Нәсимә Гариповага, Равия Булатовага Мактау грамоталары тапшырыла. Калган һәвәскәрләр КПСС өлкә комитеты, Министрлар советы һәм Мәдәният министрлыгының Мактау грамоталары белән бүләкләнә.

1965-1966 ел сезонында театр Нәсилә Гәрәева, Энҗе Зиннурова, Альберт Гыймадиев (ул әле рәссам да),

Мөҗәһит Исламов, Галия Фәтхуллина, Алмаз Хәмидуллин, А. Кириллова кебек яңа көчләр белән тулылана. Хәй Вахитның «Беренче мәхәббәт», Әнгам Атнабаевның «Ана хөкеме», Гадел Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» әсәрләре сәхнәгә менә.

«Тапшырылмаган хатлар»га 2 нче мәктәптә укыган һәм укытучы булып эшләүче Зөфәр Сәгыйтов көйләр яза. Ул җырлар, халык арасында таралып, яратып җырлана.

1966 елда коллективка автобус бүләк ителү театрның эшен җиңеләйтә. Үзешчәннәрнең үз авторы - Зәйнәп Җиһаншина барлыкка килә. Аның тарафыннан язылган, Октябрьнең 50 еллыгына багышланып куелган «Төнге шәүләләр» әсәре республика халык театрлары арасындагы бәйгедә 2 нче дәрәҗә Диплом белән бәяләнә. Алга таба халык театры үз репертуарын башка халык әсәрләре белән дә баета. Мансур Кашапов үзе дә «Чишмә җырын» яза, сәхнә әсәрләрен башка телдән дә тәрҗемә итә.

Коллектив, Октябрьнең 50 еллыгы уңаеннан һәм «Халык театры» исеме алуга биш ел тулуга багышлап, Мирсәй Әмирнең «Миңлекамал» драмасын сәхнәләштерә. Тамашаны Мирсәй Әмир үзе дә карый. Нәтиҗәдә коллективның хезмәте югары бәяләнә.

1968 елда коллектив 50 еллык юбилеен зурлап билгеләп үтә. Юбилей кичәсе истә калырлык күркәм бер вакыйга була. Коллективка югары дәүләт бүләкләре тапшырыла. М. Вахитов исемендәге икенче мәктәп коллективы исеменнән өлкән буын укытучысы Рәшидә Әхмәдиева, яшь укытучы Һаҗәр Гәрәева юбилярларга ефәк зәңгәр шәл бүләк итәләр.

ГЭС, алга таба КамАЗ төзелә башлау театр алдына тагын да җаваплы бурычлар куя. Бөтенсоюз удар комсомол төзелешенә үзешчәннәр зур өлеш кертә.

Әнгам Атнабаевның «Шоңкар», Таҗи Гыйззәтнең «Изге әманәт», Кәрим Тинчуринның «Американ», Мөхәммәт Әблиевның «Шәмсекамәр», Нәкый Исәнбәтнең «Рәйхан», Сәет Шәкүровның «Тормыш бусагасында» һ.б. пьесалар буенча куелган спектакльләр уңыш белән бара. Моннан тыш төзүчеләр, авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре алдында концертлар, агитбригада чыгышлары, очрашулар оештырыла.

Театрның офыклары көннән-көн киңәя. 1973 елда халык театры, Ульяновскида оештырылган зона смотрында Таҗи Гыйззәтнең «Бишбүләк» спектаклен күрсәтеп, беренче урынны ала. Спектакльдә автозавод төзүдә катнашкан штукатур-буяучылар Гөлзар Гыйльманова, Зимфира Гәрәева, механизатор Әнәс Ихсанов (Улы Фәнис 2 нче гимназиядә укып, сәнгать юлын сайлады), кранчы Рәшидә Кубиева һ.б. тамашачы күңелен яулый.

1975 ел халык театры өчен тагы да нәтиҗәле була. Бу елны Бөек Җиңүгә 30 ел тула, Чаллыда һәйкәл-монумент ачыла. КамАЗның беренче чиратын тапшыру вакыты якынлаша. 1974 ел ахырында мәдәният йортына капиталь ремонт ясала. Яңартылган бинада «Зәңгәр боланнар» әсәре белән берлектә Шамил Шаһгалинең сугыш темасына язылган «Таң атканда» драмасы куела.

1976 елның февралендә коллектив, Илдар Юзеевның «Соңгы сынау» драматик легендасын сәхнәләштереп, Казанда чыгыш ясый. «Чыгыш конкурсның бизәге булды», - дип бәя бирә тамашачылар. Ике кеше - лауреат, өч кеше дипломант исемнәренә лаек була.

Октябрь революциясенең 60 еллыгы якынлаша. Халык иҗатының 1 нче

Бөтенсоюз фестивале игълан ителә. Коллектив, күп эзләнүләрдән соң, Мирсәй Әмирнең «Хөррият» драмасын һәм Х. Фәтхуллинның «Күзләр» пьесасын әзерли. Ульяновск шәһәрендә узачак зона смотрында катнашканчы, СССР- ның халык артисты Габдулла Шаму- ков Чаллыга килеп, үзешчәннәргә үз киңәшләрен бирә. Спектакльне мәдәният министры урынбасары М. Низамиев кабул итә. 1 нче Бөтенсоюз фестивалендә коллектив Дипломант исеменә лаек була. Комиссия әгъзалары спектакльнең режиссурасы яхшы булуын билгеләп үтәләр. Яңа иҗат хыяллары белән кайткан коллектив тарафыннан 1978 елның 24 декабрендә «Законлы никах белән» спектакленең премьерасы уйнала. Бу спектакльдә район мәдәният йорты директоры Гөлзада Рзаева төп рольләрнең берсен уңышлы башкара.

Алга таба да коллектив үр арты үр яулый. Репертуар Таҗи Гыйззәтнең «Наемщик» музыкаль драмасы, Хәй Вахитның «Туй алдыннан», Рабит Батулланың «Кичер мине, әнкәй», Н. Анкиловның «Хатыннар», Таҗи Гыйззәтнең «Чаткылар» (кабат куела) әсәрләре белән байый. «Хатыннар» спектакле Мансур Кашаповның, үзе әйтмешли, соңгы канат кагышы була.

Алга таба «Энергетик» мәдәният сарае каршында режиссер Илдар Хаҗиев тарафыннан үзешчәннәр театры яңадан оештырыла. Ул биш ел эшли. Анда 2 нче гимназия укытучылары Фидания Ганиева, Гөлнур Гарифулли- на, укучылар актив катнаша. Үзешчәннәр Таҗи Гыйззәтнең «Башмагым» ко- медиясе, Шәриф Хөсәеновның «Әни килде» драмасы белән Казан, Әлмәт, Ижау шәһәрләрендә уңышлы чыгыш ясый. (Ф. Г. Ганиева истәлекләреннән.)



*Сулдан беренче - рус теле һәм әдәбияты укытучысы Ф. Г. Ганиева, өченче - инглиз теле укытучысы Г. Х. Гарифуллина*

## Театр үзешчәннәре - укытучылар, укучылар һәм ата-аналар

Аларның берничәсе белән та- нышыйк.

**Мансур Кашаф улы Кашапов** (1922-2004) - режиссер, Чаллы халык театрында рольләр дә башкара.

1938 елдан драмтүгәрәк әгъзасы. Сугыштан соң коллективның штаттан тыш сәнгать җитәкчесе. 1960 елдан Чаллы халык театры режиссеры. Шигырьләр, пьесалар яза, сәхнә өчен әсәрләр тәрҗемә итә.



«Хезмәт Кызыл байрагы» ордены кавалеры, ТАССР, РСФСР Югары Советлары президиумнарының Мактау кәгазьләре белән бүләкләнә. «ТРның Атказанган мәдәният хезмәткәре», «КАМАЗ төзелеше ударнигы» исеменә лаек була.

**Әминә Кашапова - Мортазина** үзешчән сәнгатьтә актив катнаша. «Зәңгәр шәл»дә чая кыз Заһирә ролен оста башкара. (Мансур Кашаповның хатыны.)

**Хәниф Гомар улы Гомәров**

(1920-?) Чаллы районы Түбән Суык-су авылында туа. Унөч яшеннән Чаллы драмтүгәрәгендә уйный башлый. Алабуга педагогия училищесына укырга керә һәм аны 1939 елда тәмамлый.



Укытучылар әзерли торган институтта укуын дәвам итә. Шуннан армиягә алына. 1941 елда пулеметчылар әзерли торган училищены лейтенант званиесендә тәмамлый. Бөек Ватан сугышын Киев тирәсендә каршылый. Кулына корал алырга да өлгермәгән командир яраланып тоткынлыкка төшә. Сугыш ахырында союзниклар тарафыннан коткарыла. Чаллыга әйләнеп кайта. 2 нче мәктәптә немец теле, математика, физкультура укыта. Кичләрен драмтүгәрәктә шөгыльләнә. ТАССР, РСФСР Югары Советлары президиумнарының Мактау кәгазьләре белән бүләкләнә. Халык театрлары Бөтенсоюз смотрында Кәрим Тинчуринның «Зәңгәр шәл» драмасында төп рольне - Булатны башкара.



*Уртада - Хәниф Гомәров*



Бөек Җиңүнең 30 еллыгына багышланган Республика смотрында халык театры Лауреат була. Уртада - Хәниф Гомәров.

**Зөфәр Ярулла улы Сәгыйтов**

(22.08.1929). Биклән авылында туа. Хезмәт юлын 14 яшеннән киномеханик булып башлый. Аннары Красноярск өлкәсе Ачинск шәһәрендәге авиация училищесына укырга керә. Аны «бик яхшы» билгеләренә тәмамлый. Украинада очкычлар төзү заводында авиация механигы булып эшли.

Туган якларына әйләнеп кайткач, Алабуга культура-агарту училищесын, аннары Казан педагогия институтының музыка факультетын тәмамлый.



Зөфәр Сәгыйтов 2 нче мәктәптә музыка, технология укыта. Иллеләп җыр авторы. Дүрт тавышка җырлаучы 200 кешелек хор оештырган укытучы һәм композитор. Халык театрына көйләр яза һәм үзе дә спектакльләрдә катнаша.

Гөлзада **Мөхәммәт кызы Рзаева** 1949 елның 16 октябрендә Чаллы шәһәрендә туа.

«Энергетик» мәдәният сарае директоры, ТР атказанган мәдәният хезмәткәре, Чаллы шәһәренең Мактаулы гражданины, «Алтын йөрәкле кеше» мактаулы исеменә лаек. Юрий Левитан аны «Бәрхет тавыш иясе» дип бәяли



*Гөлзада Рзаева истәлекләреннән:* «Театр башта «Музей рабочих специалистов» дип аталган. Мин гаиләдә унберенче бала булып дөньяга килгәнмен. Миңа кушылган Гөлзада исеменең дә Чаллы театры белән бәйле хикмәте, сере бар. 1949 елда Халык театры «Гөлзада» драмасын сәхнәгә куйган. Әнкәй бала тудыру йортыннан алып кайткач, апам миңа Гөлзада исемен кушарга тәкъдим иткән.

*2 нче мәктәптә укыганда ук мәктәптә оештырылган бер генә чарадан да читтә калмадым. Татар теле һәм әдәбияты укытучысы Анна Ивановна Солтанова-Бустерякова һәм башка укытучылар минем мөмкинлекләремне вакытында күреп алдылар, сәләтемне үстерергә ярдәм иттеләр. Казан театр училишесын- да укыганда Марсель Сәлимҗанов: «Киләчәктә син әле бу тавышың, бу осталыгың белән Н. Островскийның «Гроза»сында Кабаниханы уйнаячаксың!» - дип бәя биргән иде. 1970 елда Казанда укыганда инде мин су өстендә уздырылган республика чарасын алып бардым. Остазым миңа академия театрында калырга тәкъдим ясаса да, мине Чаллы үзенә тартты. Бер ел Әҗмәкәй культура йортында директор булып эшләгәннән соң, 1971 елда Чаллының Үзәк урамындагы мәдәният йортына директор итеп билгеләндем. «Энергетик» мәдәният сарае ачылганнан бирле шәһәрдә мәдәният тормышын җитәклим.*

*Эштән соң үзешчәннәр туп-туры мәдәният йортына кайта. Без аларның кайтуын чәй куеп көтеп алабыз. Репетициянең ярты төнгә кадәр сузылган чаклары аз булмады. Мин театрда үзем дә уйный идем. Укытучым: Хәниф абый Гомәров һәм Зәйнәп апа Җиһаншина белән бергә «Тормыш бусагасында» драмасында төп рольләрнең берсен башкардым. Ул вакытларда театрлар арасында смотрлар еш уздырыла иде. Көндәшләребез Әтнә һәм Чистай халык театрлары булды. Без Ульяновск, Казан, Куйбышев шәһәрләрендә үткәрелгән смотрларда уңышлы чыгыш ясадык.*

*Халык театры, Мансур абый Кашапов һәм 2 нче мәктәп минем тормышымда зур роль уйнадылар дип исәплим.»*

**Шмид Мөхәммәт улы Сафиуллин** - *2* нче мәктәпнең музыка һәм физкультура укытучысы. Күп кенә спектакльләрнең музыка бизәлешен эшли һәм төп рольләрдә уйный. К. Тинчуринның «Зәңгәр шәл»ендә ишан ролен бик оста башкара. М. Кашапов билгеләп үткәнчә, театрның «Халык театры» исемен яулап алуына зур өлеш кертүчеләрнең берсе.

**Хәмит Булатов** - 2 нче мәктәптә немец телен укыта. Спектакльләргә көйләр яза. Мәсәлән, шундыйларның берсе - Габдрахман Минскийның «Дуслык чишмәсе» комедиясе. Мирсәй Әмирнең «Хөррият»ендә Мәргыйзь ролен башкарып, Бөтенсоюз фестивале дипломанты була. Тормыш иптәше **Равия Булатова** - театрның актив үзешчәннәреннән берсе.

**Зәйнәп Җиһаншина** (1920-1982) - журналист, артист, драматург. Ул Чаллы районы Биклән авылында туа. М. Вахитов исемендәге 2 нче мәктәпне, Казан финанс-экономика техни кумын

тәмамлый. 1941 елдан «Коммунизм байрагы» газетасында эшли. 25 ел Чаллы халык театрында уйный, тамашачылар арасында популярлык казана. «Төнге шәүләләр» драмасы авторы. «Хезмәттәге батырлык өчен» медале кавалеры.

**Мәрьям Шәйдуллина** - сәхнәдә 1938 елдан уйный, сәхнә ветераны. Сәхнәдә уйнаган вакытта военкоматтан повестка алып сугышка китә. Сугыштан исән-сау әйләнеп кайта. «Зәңгәр шәл»дә ишан хатыны ролен бик оста башкара. (Үзешчән Бижан Хөрмәтуллиннын тормыш иптәше.)



**Камил Шәрифуллин** (25.01.1963). Мәктәптә укыган чагында **ук** татар теле һәм әдәбияты укытучысы Шамматова Гөлшат Нуровна оештырган театрда уйный, Чаллы халык театры каршындагы «Карлыгач» балалар студиясендә шөгыльләнә. Чаллы драма театрында актер, аннары «Чишмә» халыклар дуслыгы йортында директор урынбасары булып эшли.



**Әнис Ихсанов** - сәхнә ветераны. Халык театрында бик күп матур рольләр башкара. Аяз Гыйләҗевның «Кияү урлау» комедиясендә төп рольләрнең берсен уйный.

**Тәнзилә Ихсанова** - сәхнә ветераны. Хәбиб Фәтхуллинның «Күзләр» драмасында Рәисә ролен, Әнгам Атнабаевның «Законлы никах белән»ендә - Нурсәнә, Александр Коломоевның «Зәңгәр боланнар»ында



Ася рольләрен башкарып, тамашачы хөрмәтен яулый.



**Зөләйха Минһажева.** Сүз остасы, алып баручы, язучы. Халык театры каршында «Карлыгач» балалар студиясен оештыра. Халык театрында берсен- нән-берсе уңышлы рольләр башкара. Шундыйларның берсе - Таҗи Гыйззәтнең «Чаткылар» әсәрендә Гыйльмениса.

* * *

Шулай итеп, Халык театры Гражданнар сугышы, Бөек Ватан сугышы, ГЭС һәм КАМАЗ төзелеше елларында ару-талуны белми халыкка культура хезмәте күрсәтә, 1990 елның 21 декабрендә Р. Батулланың «Күбәләк булып җаның кайтыр» спектакле белән ачылачак Чаллы татар драма театрының чишмә башы була. Мәсәлән, ТРның халык артисты Булат Сәлахов, ТРның халык артисты Рафикъ Каюмов үзешчән сәхнәдә уйнап зур сәхнәгә чыгалар.

2 нче мәктәп укытучылары һәм укучыларының халык театрына тартылуының бер сәбәбен хезмәт ветераны, РСФСРның халык мәгарифе отличнигы, 98 яшьлек Анна Ивановна Солтанова-Бустерякова истәлекләре белән дәлиллик: *«Безнең мәктәп Чаллыда бердәнбер татар мәктәбе иде. Аны саклап калу өчен күп көч куярга,*

*яңа алымнар кулланырга туры килде. Шулай итеп кенә балаларга үз ана телләрендә уку мөмкинлеген саклап кала алдык. Тел-әдәбият укытуда һәм тәрбия эшендә әдипләр, композиторлар һәм җырчылар белән эзлекле очрашулар гаять йогынтылы булды. Ул очрашулар шыгрым тулы залларда зур әзерлек белән үтә, укучылар, укытучылар һәм шәһәр халкы өчен зур бәйрәм була иде. Очрашулар әдәбияттан белемнәребезне арттыра, кызыксыну уята, күңелләребезне сафландыра, рухи азык бирә иде».*

## Традиция дәвам итә

Гасырдан артык тарихы булган мәктәптән бик күп сәнгать әһелләре чыккан. Мәсәлән, ТР Халык артисткасы, опера җырчысы **Галина Казанцева** (Ул З. Я. Сәгыйтовны үзенең остазы дип саный!), Болгариядә үткәрелгән «Без XXI гасыр балалары» фестивале лауреаты, «Созвездие - 2003» бәйгесендә Гран-прига лаек булган һ.б бәйгеләр җиңүчесе, ТРның атказанган артисты Рузил Гатин.

**Динар Хөснетдинов** 2007 елда М. Вахитов исемендәге 2 гимназияне, **2011** елда Казан театр училищесын тәмамлый. Әлмәт татар драма театры артисты. «Ак чәчәкләр» фильмында - Мансур (2015), «Сөмбелә» фильмында Байрас (2020) рольләрен башкара. 2022 елда ТРның «Тантана» премиясе лауреаты булды.

Талантларны талантлы шәхесләр тәрбияли. Милли кадрларны тәрбияләүдә милли мәктәпнең роле бәһасез булу тагы бер кат расланды.

**Гөлназ Закирова.** Мәктәптә укыганда үзешчән сәнгатьтә актив катнаша. **2012** елда Н. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясен тәмамлый. Композитор-башкаручы, ТР Композиторлар берлеге әгъзасы**.** 2004, 2008 елларда «Дуслык моңы», «Яңа татар җыры» бәйгеләре лауреаты, Татар конгрессы исеменнән Азия, Европа илләрендә чыгыш ясый. Татар театрлары өчен көйләр яза. Ул иҗат иткән җырлар танылган эстрада җырчылары репертуарында яңгырый.



**Энҗе ХАРИСОВА, 2 нче гимназия укытучысы һәм музей җитәкчесе, ТР атказанган укытучысы.**